**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№12177**
**15.12.2023**

Башкарма комитетның 2016 елның 12 июлендәге 3538 номерлы Карары белән расланган өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 12 июлендәге 3538 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 16 сентябрендәге 4814 номерлы, 2017 елның 20 октябрендәге 6380 номерлы, 2018 елның 25 декабрендәге 7764 номерлы, 2019 елның 13 февралендәге 709 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында нигезләмәгә, 6 пунктның 10 пунктчасын төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов